РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск,
423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән
Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 29 июне № 28

Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы
13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә
муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

«муниципаль хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигезләр" 18 статьясындагы 18.1 пунктының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин